Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы
Кызыл Бистә авыл җирлеге Советы

КАРАР

№ 59-3 14.12.2022ел

«Җирле салымнар һәм җыемнар буенча пенялар, штрафлар буенча недоимкаларны һәм бурычларны түләтүгә һәм бетерүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен раслау турында»2011 елның 25 июлендәге 23-1 номерлы Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Кызыл Бистә авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 263-ФЗ номерлы Федераль законга бәйле рәвештә, ТР Спас муниципаль районының Кызыл Бистә авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «Җирле салымнар һәм җыемнар буенча пенялар, штрафлар буенча недоимкаларны һәм бурычларны түләтүгә һәм бетерүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен раслау турында» 2011 елның 25 июлендәге 23-1 номерлы Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Ким авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның тексты буенча «җирле салымнар һәм җыемнар буенча недоимка һәм пенялар буенча бурыч түләтүгә һәм аларны исәптән чыгаруга өметсез» сүзләрен «җирле салымнар суммасы өлешендә бурыч түләтүгә ышанычсыз» сүзләренә алмаштырырга.

2. Бу карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Кызыл Бистә, Кызыл Вал һәм Щербет торак пунктларында мәгълүмат стендларына урнаштырып, халыкка игълан ителергә тиеш, шулай ук Спас муниципаль районының интернет челтәрендәге рәсми сайтында http://spasskiy.tatarstan.ru/ һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында https://pravo.tatarstan.ru/.

Кызыл Бистә авыл җирлеге башлыгы А.В. Алиев